**УКАЗ**
РАИСА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
РӘИСЕ
**УКАЗЫ**

**Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында агач материалларын законсыз әзерләүне, транспортлауны, эшкәртүне, сатуны һәм экспортлауны кисәтү һәм туктату мәсьәләләре ведомствоара комиссиясе турында» Указына үзгәрешләр кертү хакында**

1. Татарстан Республикасы Президентының «Татарстан Республикасында агач материалларын законсыз әзерләүне, транспортлауны, эшкәртүне, сатуны һәм экспортлауны кисәтү һәм туктату мәсьәләләре ведомствоара комиссиясе турында» 2012 елның 16 маендагы ПУ-342 номерлы Указына (Татарстан Республикасы Президентының 2015 елның 4 мартындагы ПУ-233 номерлы, 2017 елның 6 октябрендәге ПУ-888 номерлы, 2018 елның 16 мартындагы ПУ-236 номерлы, 2019 елның 6 августындагы ПУ-451 номерлы, 2020 елның 8 июлендәге ПУ-387 номерлы, 2021 елның 18 июнендәге ПУ-490 номерлы, 2023 елның 21 гыйнварындагы ПУ-43 номерлы указлары һәм Татарстан Республикасы Рәисенең 2023 елның 14 апрелендәге 234 номерлы Указы нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

а) Татарстан Республикасында агач материалларын законсыз әзерләүне, транспортлауны, эшкәртүне, сатуны һәм экспортлауны кисәтү һәм туктату мәсьәләләре ведомствоара комиссиясе турында нигезләмәнең 12 пунктында «квартал» сүзен «яртыеллык» сүзенә алмаштырырга;

б) Татарстан Республикасында агач материалларын законсыз әзерләүне, транспортлауны, эшкәртүне, сатуны һәм экспортлауны кисәтү һәм туктату мәсьәләләре ведомствоара комиссиясе әгъзасы Б.М. Әхмәдиевның вазыйфасы атамасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Табигатьтән файдалану өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Идел-Кама төбәкара идарәсе җитәкчесе урынбасары (килешү буенча)».

2. Әлеге Указ аңа кул куелган көннән үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы**
**Рәисе**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ РӘИСЕ АДМИНИСТРАЦИЯСЕ • АДМИНИСТРАЦИЯ РАИСА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

**Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2024 ел, 18 май
№ 361